Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Югары Мактама авыл Башкарма комитеты

КАРАРЫ

08 апрель 2026 ел № 4

Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл Башкарма комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Югары Мактама авыл башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл Башкарма комитетының карарларының үз көчләрен югалтуын танырга:

- 2015 елның 20 ноябрендәге 24 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү Кагыйдәләре хакында»;

- 2020 елның 14 маендагы 4 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы авыл башкарма комитетының 2015 елның 20 ноябрендәге 24 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү Кагыйдәләре хакында» карарга үзгәрешләр кертү турында»;

2. Әлеге карарны Әлмәт районы Югары Мактама авылы, Октябрь урамы, 50 нче йорт, Туктар авылы, Кутуй урамы, 9 йорт йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Югары Мактама авыл башкарма комитеты җитәкчесе Н.Т.Нуриев